ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 октября 2019 г. № 5403

Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5858 нче карары белән расланган җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 маддәсе, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5858 нче карары (Башкарма комитетның 2015 елның 4 сентябрендәге 4936 нчы, 2016 елның 27 июнендәге 3281 нче, 2017 елның 31 августындагы 5059 нчы, 2018 елның 2 мартындагы 1053 нче карарлары редакциясендә) белән расланган җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый | 1) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан яисә Бердәм дәүләт юридик | 210-ФЗ санлы Федераль законның 7.1 маддәсе |

| | | |
|---|---|---|
| актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | затлар реестрыннан өземтә;<br>2) күчемсез милек объектына (1 һәм 2 бүлекләр), җир участогына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>3) күчемсез милек объектына (1 бүлек), җир участогында урнашкан капиталь төзелеш объектларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>4) территориянең карта-планы;<br>5) җир участогының топографик планы;<br>6) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) Бердәм дәүләт реестрыннан вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән, түбәндәгеләрне үз эченә алган өземтә:<br>- мәдәни мирас объектының билгеләнеше һәм фактта файдаланылуы турында мәгълүмат;<br>- ачыкланган мәдәни мирас объектын реестрга кертү турында карар кабул иткән органның исеме, әлеге карарның реквизитлары;<br>- реестрдагы теркәү номеры һәм мәдәни мирас объектын реестрга кертү датасы;<br>7) шәһәр округы коммуналь инфраструктурасын | 218-ФЗ санлы ФЗ 14 маддәсенең 2 бүлегенең 7 пункты, 24.1 маддәсе; 73-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсе;<br><br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 маддәсе 3 бүлегенең |

| | | |
|---|---|---|
| | комплекслы үстерү программасын исәпкә алып билгеләнә торган капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыруның) техник шартлары турында мәгълүмат;<br>8) территорияне межалауның расланган проекты һәм жир участогының яки жир участокларының территориянең кадастр планында урнашу схемасы (федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны, жирле әһәмиякә ия объектларны урнаштыру өчен жир участогы дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм өченче затларның хокуклары булмаган жирләрдән һәм (яки) жир участокларыннан барлыкка килгән очракта) (сервитут, жәмагать сервитутыннан тыш)). Формалаштырылган документлар пакеты ике экземплярда бирелә. | 15 пункты, 7 бүлеге,<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 маддәсенең 1.1 бүлеге |

2) 2.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр:<br>1) территорияне | РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 маддәсенең 4, 5 бүлекләре |

| | | |
|---|---|---|
| | планлаштыру буенча документлар булмау (ул булмаганда капиталь төзелеш объектларын урнаштыру рөхсәт ителмәгән очракта);<br>2) гариза бирүченең җирле үзидарә органына җир участогы урнашмаган урын буенча мөрәҗәгать итүе;<br>3) муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап җир участогына хокукы булмаган зат мөрәҗәгать итү (федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны, җирле әһәмиякә ия объектларны урнаштыру өчен җир участогы дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм өченче затларның хокуклары булмаган җирләрдән һәм (яки) җир участокларыннан барлыкка килгән очрактан тыш (сервитут, җәмәгать сервитутыннан тыш));<br>4) җирле үзидарә органы инициативасы белән аңа карата төзелгән территорияне үстерү турында һәм территорияне комплексллы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан җир участогына карата төзелгән территорияне үстерү турында яки территорияне комплекслы үстерү турында килешү нигезендә расланган территорияне планлаштыру документлары булмау (территорияне комплекслы | |

| | | |
|---|---|---|
| | үстерүне мөстәкыйль гамәлгә ашыру турында карар кабул ителү очрагыннан тыш). | |

3) 3.4.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) (алга таба – мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр) әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны (мәгълүматны) бирү турында ведомствоара запрослар (кәгазь яки ведомствоара электрон үзара хезмәттәшлек системасы аша электрон документ формасындагы документ) җибәрә.

Җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү турында гаризада булганда, җир участогыннан файдалану максаты турындагы мәгълүмат (җир участогыннан файдалану турындагы андый мәгълүмат җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә туры килмәгән очрактан тыш) яки җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән мәгълүматлар һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документлар җирле үзидарә органнары тарафыннан инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларга запрос составында бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгеченә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат белән тәэмин итүчеләргә җибәрелгән ведомствоара запрослар.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә, имзаланган көннән башлап җиде көн срокта әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин